**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йортТел. 3-44-44,факс3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/.3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 06.08.2019г

**РЕШЕНИЕ**
№39-08

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 матдәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибе турындагы» Актаныш муниципаль районы Советының 2012 елның 28 гыйнварындагы 14-01 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы “Россия Федерациясенең “Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында закон кабул ителү сәбәпле, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 матдәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнар исемлеген әзерләү тәртибе турында 28.01.2012елдан 14-01 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 бүлегендәге 3 пунктында «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Тәртипнең 2 бүлегендәге 21 пунктында «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Тәртипнең 2 бүлегендәге 22 пунктында «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Тимиров А. И. йөкләргә.

Актаныш муниципаль
районы Совет Рәисе

Э.Н. Фәттахов